Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы

Ядегәр авыл җирлеге башлыгы

# КАРАРЫ

11 ноябрь 2022 ел №5

«Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлегенең Ядегәр авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2022 елның 23 ноябренә 19 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлегенең Ядегәр авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Ядегәр авылы, Ленин урамы, 21 нче “а” йорт адресы буенча урнашкан Ядегәр авылы мәдәният йорты бинасында үткәрергә.
2. 2022 елның 26 ноябренә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлегенең Ядегәр авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Ядегәр авылы, Ленин урамы, 21 нче “а” йорт адресы буенча урнашкан Ядегәр авылы мәдәният йорты бинасында үткәрергә.
3. 2022 елның 26 ноябренә 19 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлегенең Ядегәр авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Ядегәр авылы, Ленин урамы, 21 нче “а” йорт адресы буенча урнашкан Ядегәр авылы мәдәният йорты бинасында үткәрергә.
4. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

5.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: :«1 төркем инвалидлар, көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз әниләр, 80 яшькә

җиткәннәр һәм аннан да өлкәнрәкләр, Россия Федерациясе Коралды Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлегенең Ядегәр авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2023 елда үзара салымны 2000 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Ядегәр авылында кышын-җәен юлларны карап тоту (кардан чистарту, түгү), проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;
- Ядегәр авылының С.Сәйдәш, Дуслык,Гагарин, Көнчыгыш, Ленин, Такташ урамнары буенча юлларга вак таш җәю, проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру һәм килешү буенча түләү;
- Ядегәр авылының чишмәсен һәм территориясен төзекләндерү, ремонтлау (материаллар алу) проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру һәм килешү буенча түләү;
- Ядегәр авылында энергия саклаучы лампалар, светодиод яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, төзекләндерү һәм килешү буенча түләү;
- торак пунктка керү һәм чыгу юлында видеокамералар урнаштыру һәм килешү буенча түләү;
- су белән тәэмин итү челтәрләре өчен проект-смета документларын эшләү, су белән тәэмин итү трассасын ремонтлау, су насосын алу һәм килешү буенча түләү;
- “Сабантуй” үткәрү урынының территориясен төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм килешү буенча түләү;
- Ядегәр авылы урамнарын асфальтлау, проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, экспертиза үткәрү һәм килешү буенча түләү

«РИЗА» «КАРШЫ»

6. Җыенны оештыручы итеп Ядегәр авылы башкарма комитетын билгеләргә.

7.Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Ядегәр авыл җирлеге башлыгы: А.Н.Фәйзуллин